КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 сентябрь г.Казань № 807

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы; 2014 ел, 24 февраль, 118 нче; 2014 ел, 30 апрель, 284 нче; 2014 ел, 2 июнь, 374 нче; 2014 ел, 17 июнь, 418 нче; 2014 ел, 8 июль, 473 нче; 2014 ел, 9 июль, 477 нче; 2014 ел, 25 август, 612 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы; 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы; 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче; 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы; 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы; 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы; 2015 ел, 28 июль, 549 нчы; 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 28 декабрь, 992 нче; 2016 ел, 31 март, 190 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 268 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 940 нчы; 2017 ел, 9 февраль, 73 нче; 2017 ел, 23 июнь, 423 нче; 2017 ел, 13 июль, 480 нче; 2017 ел, 21 октябрь, 802 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 1002 нче; 2018 ел, 27 июнь, 533 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1192 нче; 2019 ел, 11 февраль, 94 нче; 2019 ел, 11 март, 167 нче; 2019 ел, 28 март, 229 нчы;

2019 ел, 3 июнь, 465 нче; 2019 ел, 19 июль, 600 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 817 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1066 нчы; 2019 ел, 24 декабрь, 1184 нче; 2020 ел, 2 март, 156 нчы; 2020 ел, 24 апрель, 324 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа-ның бурыч-лары | 1. Дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген күтәрү, халыкның Татарстан Республикасы иҗтимагый-сәяси тормышында активлыгын арттыру, инновация эшчәнлеге һәм сәнәгать җитештерүен үстерү өчен шартлар тудыру.<br>2. Инновацион икътисадны формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле эшләтү һәм үстерү өчен шартлар тудыру, шулай ук аның Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү бурычларын хәл итүгә керткән өлешен арттыру.<br>2.1. Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъект-ларын үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше бурыч-ларын хәл итүгә аның өлешен арттыру.<br>3. Коммерциягә карамаган оешмаларның социаль юнәлештәге эшчәнлеген стимуллаштыру.<br>4. Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерү-чәнлеген арттыру һәм югары җитештерүчән эш урыннары санын арттыру.<br>5. Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының конку-рентлылык сәләтен дөньякүләм дәрәҗәгә кадәр күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру.<br>6. Интеллектуаль милек белән нәтиҗәле идарә итү хисабына икъти-садый өстенлекләр алуның үтемле механизмын формалаштыру.<br>7. Татарстан Республикасы территориясендә конкурентлыкка сәләтле сәнәгать җитештерүләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, кече һәм урта бизнесның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген һәм эш активлыгын арттыру»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре

Программаны финанслауның гомуми күләме 71 279 845,27853 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 62 578 648,06853 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 8 006 239,76 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 10 207,87 мең сум һәм җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 684 749,58 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,15 | 1 908 009,45 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 421 649,442 | 4 120 124,882 | 248 450,26* | 1 499,3 | 51 575,0 |
| 2018 | 5 800 952,27 | 5 700 969,9***** | 71 405,8* | 1 901,57 | 26 675,0 |
| 2019 | 12 881 971,1304 | 11 505 679,4304 | 1 345 699,7* | 2 917,0 | 27 675,0 |
| 2020 | 13 270 664,35613 | 12 713 043,05613****** | 530 898,8* | 747,5 | 25 975,0 |
| 2021 | 13 256 507,4 | 12 987 167,0 | 242 760,4* | 605,0 | 25 975,0 |
| 2022 | 5 823 297,1 | 5 107 357,6 | 697 334,5* | 605,0 | 18 000,0 |
| 2023 | 2 723 371,9 | 2 141 720,6 | 563 046,3* | 605,0 | 18 000,0 |
| 2024 | 2 451191,2 | 2 141 720,6 | 290 865,6* | 605,0 | 18 000,0 |
| Барлыгы | 71 279 845,27853 | 62 578 648,06853 | 8 006 239,76* | 10 207,87 | 684 749,58 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

*Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме ел саен бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сумы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән өлеше.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2014 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерелгән өлеше.

| | |
|---|---|
| | ****Шул исәптән 1 364,34855 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2015 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерелгән өлеше.<br>*****Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.<br>******Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган һәм 111 649,62509 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше, һәм 1 327,24 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2020 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше»; |

Программаның II бүлегендәге өченче – унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси тормышында халыкның активлыгын арттыру, инновацион эшчәнлекне һәм сәнәгать җитештерүен үстерү өчен шартлар тудыру.

2. Инновацион икътисадны формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле эшләтү һәм үстерү өчен шартлар тудыру, шулай ук аның Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү бурычларын хәл итүгә керткән өлешен арттыру.

2.1. Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүгә аның өлешен арттыру.

3. Коммерциягә карамаган оешмаларның социаль юнәлештәге эшчәнлеген стимуллаштыру.

4. Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм югары җитештерүчән эш урыннары санын арттыру.

5. Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының конкурентлылык сәләтен дөньякүләм дәрәҗәгә кадәр күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру.

6. Интеллектуаль милек белән нәтиҗәле идарә итү хисабына икътисадый өстенлекләр алуның үтемле механизмын формалаштыру.

7. Татарстан Республикасы территориясендә конкурентлыкка сәләтле сәнәгать җитештерүләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, кече һәм урта бизнесның инвестицияләр җәлеп ителешен һәм эш активлыгын арттыру.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 71 279 845,27853 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 62 578 648,06853 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 8 006 239,76 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 10 207,87 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 684 749,58 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,15 | 1 908 009,45 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 421 649,442 | 4 120 124,882 | 248 450,26* | 1 499,3 | 51 575,0 |
| 2018 | 5 800 952,27 | 5 700 969,9***** | 71 405,8* | 1 901,57 | 26 675,0 |
| 2019 | 12 881 971,1304 | 11 505 679,4304 | 1 345 699,7* | 2 917,0 | 27 675,0 |
| 2020 | 13 270 664,35613 | 12 713 043,05613****** | 530 898,8* | 747,5 | 25 975,0 |
| 2021 | 13 256 507,4 | 12 987 167,0 | 242 760,4* | 605,0 | 25 975,0 |
| 2022 | 5 823 297,1 | 5 107 357,6 | 697 334,5* | 605,0 | 18 000,0 |
| 2023 | 2 723 371,9 | 2 141 720,6 | 563 046,3* | 605,0 | 18 000,0 |
| 2024 | 2 451191,2 | 2 141 720,6 | 290 865,6* | 605,0 | 18 000,0 |
| Барлыгы | 71 279 845,27853 | 62 578 648,06853 | 8 006 239,76* | 10 207,87 | 684 749,58 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен аларга төзәтмәләр кертелергә тиеш.

*Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме ел саен бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сумы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән өлеше.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2014 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерелгән өлеше.

****Шул исәптән 1 364,34855 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2015 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерелгән өлеше.

*****Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.

******Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган һәм 111 649,62509 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше, һәм 1 327,24 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2020 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше.»;

Программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага 2 нче кушымтада:

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» | Татарстан Республикасы бюджеты | 896 009,75 | 1 139 720,66 | 1 722 097,6 | 1 687 460,55 | 1 947 977,2 | 2 039 561,8 | 1 245 971,4 | 1 038 100,5 | 1 035 841,1 | 870 148,1 | 870 148,1 | 14 493 036,76 |
| | федераль бюджет***** | | 110 236,5 | | | | | | | | | | 110 236,5»; |

«2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» | федераль бюджет******* | | | | | | 129 861,2 | 48 568,0 | 38 292,0 | 74 676,7 | | | 291 397,9 |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | | 17 738,3 | 14 500,0 | 9 957,5 | 9 957,5 | 36 660,0 | 36 760,0 | 37 050,0 | 37 450,0 | 37 450,0 | 37 450,0 | 274 973,3 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар ***** | | 3 068,7 | | | | | | | | | | 3 068,7»; |

«2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасын- | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | 977 039,45 | 1 171 388,1483 | 1 046 376,03613 | 1 000 000,0 | 1 000 000,0 | 1 000 000,0 | 1 000 000,0 | 7 194 803,63443 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| да кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» | федераль бюджет***** | - | - | - | - | 71 405,8 | 1 215 838,5 | 482 330,8 | 204 468,4 | 622 657,8 | 563 046,3 | 290 865,6 | 3 450 613,2»; |

«Программа буенча барлыгы, шул исәптән:» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Программа буенча барлыгы, шул исәптән:: | 3 669 180,12 | 3 778 805,15 | 3 202 255,210 | 4 421 649,442 | 5 800 952,270 | 12 881 971,1304 | 13 270 690,142 | 13 256 507,4 | 5 823 297,1 | 2 723 371,9 | 2 451 191,2 | 71 279 871,0644»; |

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы бюджеты | 1 794 954,55 | 1 908 009,45 | 2 457 901,0 | 4 120 124,882 | 5 700 969,900 | 11 505 679,4304 | 12 713 068,842 | 12 987 167,0 | 5 107 357,6 | 2 141 720,6 | 2 141 720,6 | 62 578 673,8544»; |

«федераль бюджет» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «федераль бюджет | 1 717 775,57 | 1 701 821,12 | 596 181,71 | 248 450,26 | 71 405,8 | 1 345 699,7 | 530 898,8 | 242 760,4 | 697 334,5 | 563 046,3 | 290 865,6 | 8 006 239,76»; |

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 603 273,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 14 493 036,76 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 110 236,5 мең сум.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>барысы</th><th>Татарстан Республикасы бюджетыннан</th><th>федераль бюджеттан</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>896 009,75</td><td>896 009,75</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 249 957,16</td><td>1 139 720,66</td><td>110 236,5</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 722 097,6</td><td>1 722 097,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 687 460,55</td><td>1 687 460,55</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 947 977,2</td><td>1 947 977,2*</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 039 561,8</td><td>2 039 561,8**</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 245 971,4</td><td>1 245 971,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 038 100,5</td><td>1 038 100,5</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 035 841,1</td><td>1 035 841,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>870 148,1</td><td>870 148,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>870 148,1</td><td>870 148,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>14 603 273,46</td><td>14 493 036,76</td><td>110 236,5</td></tr>
</table>
*Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.<br>
**Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше»;
</td>
</tr>
</table>

1 нче ярдәмче программаның I бүлегендәге «Татарстан Республикасында башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру эше «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру кысаларында алып барыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан хезмәт күрсәтү системасын камилләштерү буенча кайбер чаралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 9 август, 649 нчы карары белән расланган «2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметү, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерү һәм аларның сыйфатын яхшырту, шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр базасында» озак вакытлы максатчан программасы кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча чаралар планын («юл картасын»), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 июнь, 394 нче карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын алга таба үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») үтәү юлы белән гамәлгә ашырылды.

Башкарылган эш нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең барлык башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары эшләнде һәм тиешле норматив актлар белән расланды. Әлеге норматив хокукый актлар гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертелүгә карап актуальләштерелә. 2018 – 2019 елларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан – 180 административ регламент, җирле үзидарә органнары тарафыннан 2 200дән артык административ регламент актуальләштерелде (законнарга үзгәрешләр кертүгә һәм хезмәтләр күрсәтүнең аерым процедураларын оптимальләштерүгә бәйле рәвештә).

2020 елның 1 маена дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең 211 административ регламентлары, җирле үзидарә органнары дәрәҗәсенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре буенча 38 бертип административ регламент эшләнде һәм ведомство актлары белән расланды.

Моннан тыш, җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтү сыйфатында 2013 елдан башлап муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бертип административ регламентлары эшләнә һәм закон таләпләре үзгәрүгә карап актуальләштерелә. Әлеге бертип административ регламентлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең рәсми сайтларында урнаштырыла. 2020 елның 1 мае хәленә карата 87 бертип административ регламент формалаштырылды.

2019 елда республикада «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында эшләүдән Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан бирелә торган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталлары һәм реестрлары системасының төбәк (муниципаль) челтәренең бертип карары» программа тәэминатына (алга таба – Реестр) күчү гамәлгә ашырылды. Шуңа бәйле рәвештә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче Татарстан Республи-

касы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм республиканың җирле үзидарә органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының методологик ярдәме белән, Реестрга хезмәт күрсәтү буенча мәгълүматларны кертү буенча масштаблы эш башкарылды. 2020 елның 1 мае хәленә карата Реестрда 238 дәүләт хезмәте һәм 6 682 муниципаль хезмәт бастырып чыгарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән түбәндәгеләр расланды:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәтләре исемлеге;

Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге;

Ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру буенча эшләр башкару планлаштырыла торган беренче чираттагы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә түләүнең иң чик күләмен билгеләү тәртибе.

2012 елдан хакимият органнары карамагындагы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар белән алмашу ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче карары белән расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә, 2019 елдан башлап, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан хезмәт күрсәткәндә генә түгел, ә функцияләрне тормышка ашырганда да Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының ведомствоара һәм дәрәҗәара хезмәттәшлеген проектлаштыруны методологик яктан тәэмин итү гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында мәгълүмат» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы белән Россия Федерациясе субъектлары алдына хакимият органнары эшчәнлегенең һәм алар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасының нәтиҗәлелеген арттыру буенча яңа бурычлар куелды.

Әлеге бурычларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карары белән дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне «бер тәрәзә» принцибы буенча күрсәтү системасының

координаторы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе булдырылды.

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең (алга таба – КФҮ) төп бурычы – халык өчен «бер тәрәзә» принцибы буенча бер урында таләп ителә торган хезмәтләрдән, хакимият органнарына мөрәҗәгать итмичә, файдалану мөмкинлеген тәэмин итү.

Татарстан Республикасында КФҮ офисларының киң челтәре булдырылган («Минем документлар»), алар Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында һәм шәһәр округында, шулай ук 1 меңнән артык халкы булган Татарстан Республикасы авыл җирлекләрендә эшли.

Республиканың КФҮ системасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

республика буенча филиаллар челтәре белән «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «КФҮ» ДБУ);

һәр муниципаль районда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча «КФҮ» ДБУнең 59 үзәге һәм берничә офис – Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә урнашкан;

Казан шәһәрендә Петербург урамы, 28 нче йорт адресы (Эшмәкәр йорты) буенча 1 өстәмә офис (бизнес өчен КФҮ);

Казан шәһәрендә Җиңү проспекты, 62/4 нче йорт адрес буенча Яр Чаллы шәһәрендә Сөембикә проспекты, 16 нчы йорт адресы буенча Саклык банкы бүлеге базасында 2 Хезмәт күрсәтү үзәге (алга таба – ХКҮ);

халкы 1 меңнән артык булган авыл җирлекләрендә КФҮнең 281 территориаль-аерымланган структур бүлекчәсе (ТАСБ – еракта торып кабул итү тәрәзәсе).

Татарстан Республикасында КФҮ үзәкләре гариза бирүчеләргә (физик һәм юридик затларга) көн саен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтү күпфункциональ үзәкләре һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 нче карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән билгеләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә «бер тәрәзә» принцибы буенча 200 дән артык дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра.

Болар – федераль хакимият органнары һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары хезмәтләре, хакимиятенең төбәк органнары һәм республика оешмалары хезмәтләре, муниципаль хезмәтләр һәм башка өстәмә хезмәтләр.

Хезмәтләр исемлеге даими рәвештә арттырыла, күрсәтелгән хезмәтләр саны арта: 2016 елда – 2,7 млн. хезмәт күрсәтү факты; 2017 елда – 3,4 млн. хезмәт күрсәтү факты; 2018 елда – 3,7 млн. хезмәт күрсәтү факты; 2019 елда – 4,9 млн. хезмәт күрсәтү факты.

Гариза бирүчеләргә уңайлы булсын өчен Бердәм белешмә хезмәте – КФҮ колл-үзәге эшли, аңа барлык сораулар буенча атнага алты көн мөрәҗәгать итәргә мөмкин (шул исәптән татар телендә дә), мөрәҗәгать итүчеләргә документлар әзерлеге турында СМС-хәбәр җибәрелә.

2018 елдан гариза бирүче берничә хезмәт күрсәтүгә бер гариза биргәндә, КФҮләрдә аерым хезмәт күрсәтүләргә карата комплекслы соратып алу кысаларында документлар бирү кертелде, бу исә кабул итү вакытын шактый киметә. Күрсәтелгән федераль дәүләт хезмәтләренең сыйфатын бәяләү максатларында КФҮнең барлык филиалларында һәм бүлекләрендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы заказы буенча булдырылган «Сезнең контроль» дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингының мәгълүмати-аналитика системасы кулланыла.

Федераль хакимият органы хезмәтеннән файдаланган гражданнар, шул исәптән аның буенча республиканың КФҮ филиалларына һәм бүлекләренә мөрәҗәгать иткәндә, үзләре өчен иң уңайлы ысулны сайлап, хезмәт сыйфатын бәяләү мөмкинлегенә ия:

«0919» рәсми кыска номерыннан түләүсез СМС-сораштыруда катнашу;

vashkontrol.ru «Сезнең контроль» мәгълүмати-аналитика системасы сайтында хакимият органы яки «КФҮ» ДБУ эше турында бәяләмә калдыру (шул исәптән сылтама буенча mfc16.tatarstan.ru КФҮнең рәсми сайты аша);

КФҮ филиалларында һәм бүлекләрендә һәм республика хакимият органнарында урнаштырылган «Электрон хөкүмәт» инфоматлары аша бәя калдыру.

Шулай итеп, 2018 елның эш йомгаклары буенча дәүләт хезмәтләре сыйфатын мониторинглауның мәгълүмати-аналитика системасы (ДХСМ МАС, «Сезнең контроль») нигезендә, гражданнар һәм эшмәкәрлек субъектларының «КФҮ» ДБУдә хезмәт күрсәтү сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсе 97 процент тәшкил итте, 2019 елда – 98,16 процент, бу федераль нормативтан шактый артып китә (кимендә 90 процент).

Юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә республикада шулай ук билгеле бер эш башкарылды. «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында:

төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләренең бердәм реестры формалаштырылды;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе расланды;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе расланды;

Татарстан Республикасының барлык министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлары эшләнде;

төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда Тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентларның бердәм реестры формалаштырылды һәм актуаль халәттә тотыла;

төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәләренә мониторингы үткәрелә;

2010 елдан башлап, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле эшчәнлек тармакларында дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм әлеге тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәләренә турында докладлар әзерләү хакында» 2011 ел, 13 август, 676 нчы карары нигезендә тикшерү (күзәтчелек) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча статистик белешмәләр һәм еллык докладлар әзерләү гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы нигезендә 2014 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе субъектларында эшмәкәрлек һәм башка эшчәнлек субъектлары, шулай ук тулаем граждан җәмгыяте өчен артык административ җайга салуны һәм нигезсез артык чыгымнарны булдырмауга юнәлдерелгән җайлау йогынтысын бәяләү процедурасын закон белән беркетү каралган.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Россия Федерациясе субъектларында җайга сала торган йогынтыны бәяләү процедурасын кертү буенча методик тәкъдимнамәләргә таянып, Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан кабул ителүче (чыгарылучы) Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив хокук актларының һәм норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын ачык бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карары белән эшләнгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан кабул ителүче (чыгарылучы) Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив хокук актларының һәм норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын ачык бәяләү тәртибе расланды. Җирле үзидарә органнары өчен җайга сала торган йогынтыны бәяләү процедурасы 2015 елдан билгеләнгән тәртиптә федераль таләпләр нигезендә кертелде. Җайга сала торган йогынтыны бәяләү инструменты хакимият органнары эшенең яңа юнәлеше булып тора, һәм республикада аны тулы күләмдә куллану өчен барлык тармак министрлыклары һәм ведомстволары хезмәткәрләрен бу эшкә тиешле өйрәтү зарури.»;

1 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы» бүлекчәсенең унбенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарын һәм җирле үзидарә органнарын мәгълүмати тәэмин итү һәм үз функцияләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты Дәүләт заказы кысаларында мәгълүмати-аналитика

материалларын әзерләү чараларын тормышка ашыра. Әлеге материалларны кулланучыларга бирү заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып гамәлгә ашырыла. Дәүләт заказы кысаларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре мониторингы, аерым хуҗалык итүче субъектларның икътисадый үз-үзен тәэмин итү дәрәҗәсе мониторинглары, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру индикаторлары мониторингы, Россия Федерациясе Президенты указларын үтәү мониторингы, Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсеш мониторингы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында ярлылык дәрәҗәсе мониторингы үткәрелә, шулай ук фәнни-тикшеренү эшләре һәм социологик тикшеренүләр үткәрелә. Турыдан-туры чит ил инвестицияләре буенча мәгълүматлар Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан үз рәсми сайтында (https://cbr.ru) «Статистика / Макроикътисадый финанс статистикасы / Тышкы сектор статистикасы / Турыдан-туры инвестицияләр / Операцияләр» бүлегендә резидентлар теркәлгән субъектлар буенча хисап чоры тәмамлангач 195 календарь көннән соң ачык файдаланудa куела. МСИҮТ резидентлары буенча мәгълүматлар Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан рәсми сайтта (https://economy.gov.ru/) «Өстенлекле юнәлешләр / Төбәк үсеше / Территорияләрне үстерү инструментлары (МИ, МҮТ) / Алгарышлы үсеш территориясе / Монопрофильле муниципаль берәмлекләр территориясендә төзелгән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестры» бүлегендә ачык рәвештә тәкъдим ителә. Мәгълүматлар, хисап чоры тәмамлангач, 25 көннән соң тапшырыла.»;

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

«Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 603 273,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 14 493 036,76 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 110 236,5 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | барысы | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 896 009,75 | 896 009,75 | - |
| 2015 | 1 249 957,16 | 1 139 720,66 | 110 236,5 |
| 2016 | 1 722 097,6 | 1 722 097,6 | - |
| 2017 | 1 687 460,55 | 1 687 460,55 | - |
| 2018 | 1 947 977,2 | 1 947 977,2* | - |
| 2019 | 2 039 561,8 | 2 039 561,8** | - |
| 2020 | 1 245 971,4 | 1 245 971,4 | - |
| 2021 | 1 038 100,5 | 1 038 100,5 | - |
| 2022 | 1 035 841,1 | 1 035 841,1 | - |
| 2023 | 870 148,1 | 870 148,1 | - |
| 2024 | 870 148,1 | 870 148,1 | - |
| Барлыгы | 14 603 273,46 | 14 493 036,76 | 110 236,5 |

*Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.

**Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше.»;

1 нче Ярдәмче программага теркәлгән 1, 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашуга субсидияләр бирүне тәэмин итү.<br>3. Яшьләр эшмәкәрлеген үстерүгә булышлык күрсәтү.<br>4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына «бер тәрәзә» принцибы буенча хезмәтләр күрсәтүне оештыру.<br>5. «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына булышлык күрсәтү» илкүләм проектына керә торган федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын тормышка ашыру кысаларында эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару шартларын яхшырту.<br>6. Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле ситуациянең начараюы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны җәлеп итәргә планлаштырыла торган финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="2">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны җәлеп итәргә планлаштырыла</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 10 645 416,83443 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 7 194 803,63443 мең сум*, шулай ук җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 3 450 613,2 мең сум*.<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Татарстан Республикасы</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла</td><td>Барысы</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| торган финанслау күләмнәре | | бюджеты акчасы | торган федераль бюджет акчасы | |
| | 2018 | 977 039,45 | 71 405,8* | 1 048 445,25* |
| | 2019 | 1 171 388,1483** | 1 215 838,5* | 2 387 226,6483** |
| | 2020 | 1 046 376,03613** | 482 330,8* | 1 528 706,83613** |
| | 2021 | 1 000 000,0 | 204 468,4* | 1 204 468,4* |
| | 2022 | 1 000 000,0 | 622 657,8* | 1 622 657,8* |
| | 2023 | 1 000 000,0 | 563 046,3* | 1 563 046,3* |
| | 2024 | 1 000 000,0 | 290 865,6* | 1 290 865,6* |
| | Барлыгы | 7 194 803,63443** | 3 450 613,2** | 10 645 416,83443** |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга ел саен тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>*Федераль бюджет акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме ел саен бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә.<br>**Шул исәптән 111 649,62509 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше, һәм 1 327,24 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2020 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше»; | | | |

«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзмәшгульләр өчен салым режимын кертүне исәпкә алып, үз статусын теркәгән үзмәшгуль гражданнар санын 65,5 мең кешегә кадәр (арта бара торган йомгак белән);»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына микрофинанс оешмаларының гамәлдәге микрозаймнары санын 809 берәмлеккә кадәр (арта бара торган йомгак белән);»;

2 нче ярдәмче программаның II бүлегендә:

унынчы – унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле ситуациянең начараюы шартларында КУЭ булышлык күрсәтү.

Ярдәмче программаның төп чаралары Ярдәмче программаның максатыннан һәм бурычларыннан чыгып формалаштырылды. Шул ук вакытта, һәр мәсьәләне хәл итү кысаларында, эшмәкәрләр санын арттыру өлешендә дә, бизнесны үстерү өлешендә дә, яңа эш урыннары булдыруны күздә тоткан эшмәкәрлеккә ярдәм итүгә һәм аны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар каралган.»;

түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

«2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү чараларын эшләгәндә эшмәкәрләрнең бәйсез сорашып белешүләре мәгълүматлары исәпкә алынды.»;

2 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирнамәсе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирнамәсе

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыру бурычын гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге чаралар каралачак:

микрозаймнар бирү механизмнарын үстерү;

КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтүнең гарантия механизмнарын үстерү;

Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекнең экспорт юнәлешле субъектларына ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

Социаль өлкә инновацияләре үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын кластер нигезендә үстерү һәм кооперацияләү үзәген үстерү;

Бизнес-инкубацияләү һәм кластер нигезендә үстерү үзәген үстерү;

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын гамәлгә ашыру компетенцияләре төбәк үзәге эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү;

җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын субсидияләү («Лизинг-грант»);

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү;

туклану продуктларын һәм ризык алып килеп бирү хезмәтләренә түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашуга субсидияләр бирүне тәэмин итү бурычын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге чаралар каралачак:

дәүләт һәм (яки) муниципаль милек рәвешләрендәге сәнәгать паркларын төзү;

«Арча» сәнәгать паркын төзү;

«Буа» сәнәгать паркын төзү;

Ютазы муниципаль районында «Урыссу» сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү;

бизнес-инкубацияләү процессларын үстерү һәм бизнес-инкубаторларның агымдагы эшчәнлеген тәэмин итү.

Яшьләр эшмәкәрлеген үстерүгә булышлык күрсәтү бурычын тормышка ашыру кысаларында 30 яшькә кадәрге физик затларны эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү чаралары каралачак.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына «бер тәрәзә» принцибы буенча хезмәтләр күрсәтүне оештыру бурычын тормышка ашыру кысаларында бизнес өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күпфункцияле үзәкләрдә хезмәтләр күрсәтү дәвам итәчәк.

«Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына булышлык күрсәтү» илкүләм проектына керә торган федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын тормышка ашыру кысаларында эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару шартларын яхшырту бурычын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге чаралар күздә тотылачак:

төбәк гарантия оешмасын үстерү;

дәүләт микрофинанс оешмасын үстерү;

«Минем бизнес» үзәкләрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хезмәтләр күрсәтү, сервислар һәм ярдәм итү чаралары комплексын күрсәтү;

моношәһәрләрдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын тизләтеп үстерү максатларында, төбәк гарантия оешмасын үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлекнең экспортка юнәлдерелгән субъектларына ярдәм күрсәтүне яраштыру үзәген үстерү;

«Теләче» сәнәгать паркының беренче чиратын төзү, 2 нче этап;

«Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк төзү («Тасма-Инвест-Торг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте), 3 нче этап;

«Саба» индустриаль паркының беренче чиратын төзү;

«Саба» индустриаль паркының беренче чиратын төзү буенча авторлык күзәтчелеген алып бару;

шәхси сәнәгать паркларын булдыру һәм үстерү;

эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү һәр максатчан төркем өчен үз бизнесын булдыруга булышлык күрсәтү чараларын (башлап җибәрүче эшмәкәрләр берләшмәләрен оештыруга ярдәм күрсәтүне һәм остазлык институтын үстерүне кертеп) тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы территориясендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану буенча пилот проектын тормышка ашыру.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле рәвештә, ситуация начараюы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү бурычын гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге чаралар каралачак:

2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле рәвештә, ситуация начараюы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кичектергесез ярдәм күрсәтү өчен төбәк гарантия оешмасын капиталлаштырып бетерү;

2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле рәвештә, ситуация начараюы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына

кичектергесез ярдәм чараларын күрсәтү өчен дәүләт микрофинанс оешмасын капиталлаштырып бетерү;

сәнәгать (индустриаль) паркларның, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерү өчен 2020 елның апрелендә мөлкәт арендасыннан алынып бетмәгән керемнәре күләмендә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү;

сәнәгать (индустриаль) паркларның, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерү өчен 2020 елның маенда мөлкәт арендасыннан алынып бетмәгән керемнәре күләмендә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү;

сәнәгать (индустриаль) паркларның, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерү өчен 2020 елның июнендә мөлкәт арендасыннан алынып бетмәгән керемнәре күләмендә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү.

Моннан тыш башка чаралар каралган, шул исәптән:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм үз бизнесын оештыруны популярлаштыру буенча кампанияләр оештыру;

Татарстан Республикасында хакимият белән бизнесның үзара хезмәттәшлеге системасын оештыру;

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү»;

«Теләче» сәнәгать паркының беренче чиратын (2 нче этап) төзүгә һәм «Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк («Тасма-Инвест-Торг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, 3 нче этап) булдыруга каралган акчаны максатчан тоту өчен төзелеш күзәтчелеге;

«Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк («Тасма-Инвест-Торг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, 3 нче этап) булдыруга каралган акчаны максатчан тоту өчен төзелеш күзәтчелеге;

статистика мәгълүматын әзерләү һәм тапшыру буенча мәгълүмати хезмәтләр күрсәтү;

конкурентлык мохитен мониторинглау;

сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарәче компанияләренә һәм резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар рәвешендә ярдәм күрсәтү.

Максатлар һәм бурычлар яктылыгында Ярдәмче программаның төп чаралары исемлеге аңа теркәлгән кушымтада китерелгән.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2018 – 2024 еллар.»;

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 10 645 416,83443 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 7 194 803,63443 мең сум*, шулай ук җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 3 450 613,2 мең сум*.

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | Барысы |
|---|---|---|---|
| 2018 | 977 039,45 | 71 405,8* | 1 048 445,25* |
| 2019 | 1 171 388,1483** | 1 215 838,5* | 2 387 226,6483** |
| 2020 | 1 046 376,03613** | 482 330,8* | 1 528 706,83613** |
| 2021 | 1 000 000,0 | 204 468,4* | 1 204 468,4* |
| 2022 | 1 000 000,0 | 622 657,8* | 1 622 657,8* |
| 2023 | 1 000 000,0 | 563 046,3* | 1 563 046,3* |
| 2024 | 1 000 000,0 | 290 865,6* | 1 290 865,6* |
| Барлыгы | 7 194 803,63443** | 3 450 613,2** | 10 645 416,83443** |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга ел саен, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.

*Ярдәмче программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме ел саен федераль бюджеттан бюджетларына субсидия бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә.

**Шул исәптән 111 649,63 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше, һәм 1 327,24 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән алынган акчаның үзләштерелми калган, 2020 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше.»;

2 нче ярдәмче программаның V бүлегендә:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзмәшгульләр өчен салым режимын кертүне исәпкә алып, үз статусын теркәгән үзмәшгуль гражданнар санын 65,5 мең кешегә кадәр (арта бара торган йомгак белән) арттыру;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына микрофинанс оешмаларының гамәлдәге микрозаймнары санын 809 берәмлеккә кадәр (арта бара торган йомгак белән) арттыру;»;

2 нче ярдмәче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программага кушымтада:

1.3 пунктның 12 графасында «1» санын «4» санына алмаштырырга;

4.1 пунктның 13 графасында «350» саннарын «412» саннарына алмаштырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.1. | Татарстан Республикасының югары белем бирү оешмалары һәм һөнәр белеме бирү оешмаларында укучылар һәм студентлар арасында грант алу өчен конкурс үткәрүгә СЮККОга субсидияләр бүлеп бирү | ТР ФһММ, СЮККО (килешү буенча) | 2014 – 2018 еллар | грант алучылар саны, кеше | 3 014 | 3 000 | 3 000 | 3 000 | 2 919 | 3 000 | - | - | - | - | - | - | 25 000,0 ТРБ | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| | | ТР ЯЭСМ, СЮККО (килешү буенча) | 2019 – 2024 еллар | грант алучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | 5 792 | 5 792 | 5 792 | 5 792 | 5 792 | 5 792 | агымдагы эшчәнлек кысаларында»; | |

5.8 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар әдәбиятын саклау, үстерү, популярлаштыру буенча чаралар үткәрү, шул исәптән татар әдәбиятын рус, инглиз һәм башка телләргә тәрҗемә итүне оештыру»;

«2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче програм-маның | 1. Татарстан Республикасы предприятиеләрен хезмәт җитештерүчән-леген арттыруга юнәлдерелгән нәтиҗәле үзгәртеп коруларны үткәрүгә стимуллаштыру. |

| | |
|---|---|
| бурычлары | 2. Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм арттыру өчен агымдагы (инфраструктура, ресурс (шул исәптән кадрлар) һәм административ) чикләүләрне бетерү һәм уңайлы тышкы шартлар тудыру.<br>3. «Сакчыл җитештерү» методикасы принципларын һәм инструментларын файдаланып, Татарстан Республикасы предприятиеләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру.<br>4. Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча системалы чаралар» һәм «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм күрсәтү» төбәк проектларын тормышка ашыру»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 569 439,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 291 397,9 тыс.рублей, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 274 973,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 3 068,7 мең сум. |

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан | федераль бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2015 | 20 807,0 | 17 738,3 | - | 3 068,7 |
| 2016 | 14 500,0 | 14 500,0 | - | - |
| 2017 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| 2018 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| 2019 | 166 521,2 | 36 660,0 | 129 861,2* | - |
| 2020 | 85 328,0 | 36 760,0 | 48 568,0* | - |
| 2021 | 75 342,0 | 37 050,0 | 38 292,0* | - |
| 2022 | 112 126,7 | 37 450,0 | 74 676,7* | - |
| 2023 | 37 450,0 | 37 450,0 | - | - |
| 2024 | 37 450,0 | 37 450,0 | - | - |
| Барлыгы | 569 439,9 | 274 973,3 | 291 397,9 | 3 068,7 |

| | |
|---|---|
| | *Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан акча «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 459-ФЗ номерлы Федераль закон, «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге ФЗ-380 номерлы Федераль закон нигезендә каралган; |

4 нче ярдәмче программаның I бүлегендәге җитмешенче абзацында «сәнәгать, авыл хуҗалыгы, транспорт, төзелеш» сүзләрен «икътисадның чимал булмаган база тармаклары исемлеге Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектының, предприятиенең, тармакның хезмәт житештерүчәнлеге күрсәткечләрен исәпләү методикасын һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының аерым күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында» 2018 елның 28 декабрендәге 748 номерлы боерыгында (Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектының, предприятиенең, тармакның хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткечләрен исәпләү методикасын һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының аерым күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 748 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектының, предприятиенең, тармакның хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткечләрен исәпләү методикасына үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 15 октябрь, 659 нчы боерыгы белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) китерелгән;»;

4 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге җиденче абзацында «федераль проектлар чараларын» сүзләрен «төбәк проектларын» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

<table>
<tr><td rowspan="5">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="5">Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 569 439,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 291 397,9 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 274 973,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 3 068,7 мең сум.</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Ел</td><td colspan="4">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td rowspan="2">барлыгы</td><td colspan="3">шул исәптән</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджетыннан</td><td>федераль бюджеттан</td><td>бюджеттан тыш чыганаклардан</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>20 807,0</td><td>17 738,3</td><td>-</td><td>3 068,7</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2016 | 14 500,0 | 14 500,0 | - | - |
| | 2017 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| | 2018 | 9 957,5 | 9 957,5 | - | - |
| | 2019 | 166 521,2 | 36 660,0 | 129 861,2* | - |
| | 2020 | 85 328,0 | 36 760,0 | 48 568,0* | - |
| | 2021 | 75 342,0 | 37 050,0 | 38 292,0* | - |
| | 2022 | 112 126,7 | 37 450,0 | 74 676,7* | - |
| | 2023 | 37 450,0 | 37 450,0 | - | - |
| | 2024 | 37 450,0 | 37 450,0 | - | - |
| | Барлыгы | 569 439,9 | 274 973,3 | 291 397,9 | 3 068,7 |
| | *Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына акча «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2018 елның 29 ноябрендәге ФЗ-459 номерлы Федераль закон, «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге ФЗ-380 номерлы Федераль закон нигезендә каралган; | | | | |

4 нче ярдәмче программаның IV бүлегендәге уникенче абзацында «2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 802 нче карары белән» сүзләрен өстәргә.»;

4 нче ярдәмче программаның V бүлегендәге «Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү индикаторлары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү индикаторлары

| Индикаторлар исеме | Максатчан индикаторлар | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2014 ел (бәя) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Республика предприятиеләрендә хезмәт житештерүчәнлеге индексы, үткән елга карата чагыштырма бәяләрдә процент | 101,9 | 100,5 | 101,5 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Ярдәмче программада катнашучы предприятиеләрдә хезмәт житештерүчәнлеге индексы, үткән елга карата чагыштырма бәяләрдә процент | - | - | - | 105,0 | 105,5 | - | - | - | - | - | - |
| Татарстан Республикасы икътисадының чимал булмаган база тармакларының эре һәм урта предприятиеләрендә хезмәт житештерүчәнлеге арту, үткән елга карата процент | - | - | - | - | - | 102,2 | 103,1 | 103,9 | 104,5 | 105,2 | 106,3 |
| Республика предприятиеләрендә эш урыннарының гомуми санында югары житештерүчәнлекле эш урыннары өлеше, процент | 30,8 | 32,1 | 33,6 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармаклары предприятиеләрендәге эш урыннарының гомуми санында югары житештерүчәнлекле эш урыннары саны үсү темпы, процент | - | - | - | 103,0 | 105,0 | 106,0 | 108,0 | 108,5 | 108,6 | 108,7 | 108,9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Илкүләм проект чараларын тормышка ашыруга җәлеп ителгән һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән хезмәттәшлек итү турында килешүгә кул куйган икътисадның чимал булмаган база тармакларының эре һәм урта предприятиеләре саны, берәмлек (арта бара торган йомгак белән) | - | - | - | - | - | кимендә 63 | кимендә 89 | кимендә 130 | кимендә 211 | кимендә 286 | кимендә 351 |
| «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» илкүләм проекты чараларын төбәк идарәсенә кертүдә катнашучы предприятиеләр саны (төбәк компетенцияләр үзәкләре белән – ТКҮ), берәмлек (арта бара торган йомгак белән) | - | - | - | - | - | кимендә 22 | кимендә 38 | кимендә 54 | кимендә 74 | кимендә 94 | кимендә 114 |
| «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» илкүләм проекты чараларын мөстәкыйль рәвештә кертүдә катнашучы предприятиеләр саны, берәмлек (арта бара торган йомгак белән) | - | - | - | - | - | кимендә 20 | кимендә 22 | кимендә 37 | кимендә 84 | кимендә 124 | кимендә 161 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төбәк идарәсе астында (ТКҮ белән) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру чараларын тормышка ашыру кысаларында катнашучы предприятиеләрнең өйрәтелгән хезмәткәрләре саны, кеше (арта бара торган йомгак белән) | - | - | - | - | - | 192 | 368 | 528 | 728 | 928 | 1 118 |
| Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру чараларын мөстәкыйль рәвештә тормышка ашыру кысаларында катнашучы предприятиеләрнең өйрәтелгән хезмәткәрләре саны, кеше (арта бара торган йомгак белән) | - | - | - | - | - | 200 | 216 | 306 | 588 | 768 | 1 094»; |

4 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2015 – 2021 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программаның I бүлегендәге «Кластерда катнашучылар (Ярдәмче программада катнашучылар)» бүлекчәсенең 3 нче пунктында:

«Хитон-пласт» компанияләре төркеме» сүзләрен «Хитон Пласт 2» ҖЧҖ» сүзләренә алмаштырырга, «Мефро уилз Руссиа Завод Заинск» ҖЧҖ» сүзләрен «Аккурайд Уилз Руссиа» ҖЧҖ» сүзләренә алмаштырырга;

«ЭНТЭХ» ҖЧҖ» сүзләреннән соң «Эко-Сила-НЧ» ҖЧҖ», «Пласт Инжиниринг» ҖЧҖ», «Зиас Машинери Поволжье» ҖЧҖ», «РТИ-КОМПОНЕНТ» ҖЧҖ», «Завод Детали Интерьера» ҖЧҖ», «Техно-Логика» ҖЧҖ», «Органик парк» ҖЧҖ», «Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ», «Бетон заводы» ҖЧҖ», «ХАЙЕР ИНДАСТРИ РУС» ҖЧҖ», «КЭР – Инжиниринг» ҖЧҖ», «ТехноАрск» ҖЧҖ», «ЛМР Пласт» ҖЧҖ», «Квадро-Тойс» ҖЧҖ», «СпецПромПрогресс» ҖЧҖ», «Цеолиты Поволжья» ААҖ» сүзләрен өстәргә;

5 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Төп чаралар тасвирламасы» бүлекчәсенең җиденче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булган Кластерда катнашучыларга мәгълүмати, консультация, финанс һәм башка дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән

(шул исәптән әлеге дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы кысаларында) аерым игътибар биреләчәк. Шулай ук кластер инициативаларына ярдәм күрсәтү максаты белән Кластерда катнашучыларга техник-икътисадый нигезләмәләр һәм бизнес-планнар эшләү, маркетинг тикшеренүләре үткәрү, сертификацияләү, патентлау һәм Кластер нигезендә үстерү үзәге эшчәнлеге юнәлешләре буенча башка хезмәтләр күрсәтеләчәк.»;

«2016 – 2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа паспортының «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2021 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>интеллектуаль милек өлкәсендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын булдыру;<br>интеллектуаль милек өлкәсендә функциональ юнәлешләрне үстерү (интеллектуаль милек булдыру, аны саклау, бәяләү, яклау һәм аның хокукларын тәэмин итү);<br>ведомство (тармак) дәрәҗәсендә, фән һәм мәгариф учреждениеләрендә, иҗат, җитештерү һәм сәүдә өлкәләре оешмаларында интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсендә эшне камилләштерү;<br>иҗат хезмәткәрләре (новаторлар), шулай ук яңа эш урыннары булдыру һәм конкурентлыкка сәләтле продукция чыгару өчен интеллектуаль милекне кулланучы хуҗалык итү субъектлары эшчәнлеге, интеллектуаль милке әһәмияте дәрәҗәсен арттыру;<br>предприятиеләрнең уйлап табу активлыгын арттыру һәм Татарстан Республикасы икътисады тармакларының фәнни-технологик үсешен стимуллаштыру;<br>инновацион проектларны сату базарларына чыгару һәм җитештерү өлкәсенә инновацияләр кертү хисабына бюджетның барлык дәрәҗәләренә салым керемнәрен арттыру;<br>фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен башкару барышында булдырылган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен гамәли кулланганда бюджет акчасын файдалану нәтиҗәлелеген арттыру;<br>республика товар җитештерүчеләренең халыкара конкурентлык сәләтен арттыру һәм тышкы базарларда |

| | |
|---|---|
| | технологияләрне саклау;<br>Татарстан Республикасы җитештерүенең гомуми күләмендә чимал булмаган продукцияне экспортлау өлешен арттыру;<br>дөньякүләм дәрәҗәсендә Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру»; |

6 нчы ярдәмче программаның I бүлегендә:

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) төбәк хуҗалык итүче субъектларының уйлап табу, патент-лицензия һәм инновацион эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы икътисадый, хокукый һәм оештыру шартларын тудыруга, фәнне үстерү, инновацияләр һәм интеллектуаль милекне коммерцияләштерү буенча федераль һәм төбәк максатчан программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген арттыруга булышлык күрсәтү максатларында Роспатент һәм Татарстан Республикасы арасында хезмәттәшлек турындагы килешүдә каралган, шулай ук Татарстан Республикасында интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм индивидуальләштерү чараларына хокуклар белән идарә итү буенча тәкъдимнамәләр кертү кысаларында Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Роспатент һәм Татарстан Республикасы арасында Татарстан Республикасында интеллектуаль милек өлкәсен үстерүгә ярдәм күрсәтү кысаларында үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә каралган чаралар комплексы;»;

утыз тугызынчы абзацта «максатчан» сүзен «дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

кырык җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе һәм аның төбәкләрен инновацион үстерүнең өстенлекле бурычларын хәл итүгә системалы якын килү зарур, дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм физик затлар көчләрен берләштерү кирәк.

Әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен интеллектуаль милекне саклау һәм аның белән идарә итү буенча төбәк интеграцияләнгән комплексын булдыру кирәк. Аның элементлары булып «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе базасында оештырылачак Республика технологияләр трансферы үзәге һәм Татарстан Республикасының интеллектуаль милек өлкәсендәге компетенцияләр үзәге торачак.

Республика технологияләр трансферы үзәге Татарстан Республикасының төбәк инновацион системасын формалаштыруда һәм аны Россиянең милли инновацион системасына интеграцияләүдә төп элементларның берсе булачак.

Интеллектуаль милек өлкәсендә технологияләр трансферына хезмәт күрсәтә торган компетенцияләр үзәге түбәндәге функциональ юнәлешләрне берләштерәчәк:

интеллектуаль милекне саклау;

интеллектуаль милекне бәяләү һәм исәпкә алу;

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокуклар белән идарә итү;

интеллектуаль милекне файдалануны мониторинглау һәм законнарны үтәү;

интеллектуаль милек өлкәсендә мәгълүмат алмашуның интеграцияләнгән мәйданчыгын – «Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы»

мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитик системасын формалаштыру;

патент-мәгълүмат, консультация һәм юридик хезмәтләр күрсәтү;

интеллектуаль милек өлкәсендә өстәмә белем бирү.

Төп бурычны хәл итүдән – фәнни-мәгариф өлкәсе оешмалары, компанияләр һәм предприятиеләр арасында технологик хезмәттәшлек урнаштыруга булышлык күрсәтүдән тыш, бу Татарстан Республикасының фәнни-техник һәм инновацион сәясәтен гамәлгә ашыру буенча конкрет чараларга күчәргә, инновацион потенциалы югары булган районнардан (Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре, Иннополис шәһәре) Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләренә тәҗрибәсен тарату өчен мөмкинлекләр булдырырга, республика инновацион инфраструктурасының кадрлар потенциалын үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

Интеллектуаль милек базарын үстерүнең мөһим өлеше булып төбәк брендын формалаштыру тора.

Роспатент мәгълүматлары буенча, бүгенге көндә республикада товарның барлыкка килү урынының ике исеме генә теркәлгән. Товарның килеп чыгу урыны атамасын куллану белән кызыксыну Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре администрациясе ягыннан да күрсәтелергә тиеш. Бу товарның килеп чыгу урыны атамасының конкрет территориягә күрсәтүенә бәйле, аның географик мохите товарның аерым үзенчәлекләрен билгели. Индивидуальләшү чараларын нәтиҗәле файдалану республика икътисады үсешенә сизелерлек өлеш кертүне тәэмин итәргә мөмкин, республиканың танылуын һәм җәлеп итүчәнлеген арттыруның нигезе булачак, бу аның үсешенә инвестицияләр кертү өчен уңайлы шартлар тудырачак. Мондый инвестицияләр эшмәкәрлекне, кече һәм урта бизнесны үстерүгә, яңа эш урыннарын булдыруга, туризмны, бигрәк тә агротуризмны үстерүгә, авыл җирлекләрен саклауга юнәлдерелергә мөмкин.

Эшмәкәрлек җәмәгатьчелекләренә товарның килеп чыгу урыны атамаларын теркәүгә һәм тиешле маркировкалы продукцияне чит ил базарларына чыгаруда булышлык күрсәтүгә, күмәк товар билгеләрен булдыруда һәм теркәүдә ярдәм күрсәтүгә, Татарстан Республикасы товар җитештерүчеләрен һәм продукциясен популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга стимуллаштырырга кирәк.

Интеллектуаль милек базарын үстерү буенча күрсәтелгән бурычлар әлеге Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында хәл ителергә мөмкин.»;

6 нчы ярдәмче программаның II бүлегендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа интеллектуаль милек өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыруга һәм республиканың конкурентлыкка сәләтле икътисадын булдыру өчен уңайлы шартлар тудыруга, фәнни-техник нәтиҗәләрне эффектив файдалануга һәм Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү бурычларын хәл итүгә, шулай ук төбәк инновацион инфраструктурасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.»;

6 нчы ярдәмче программаның V бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы җитештерүенең гомуми күләмендә чимал булмаган продукцияне экспортлау өлешен арттыруга;

Татарстан Республикасының инновацион һәм технологик үсеше шартларын булдыру өчен интеллектуаль милек базары инфраструктурасын үстерүгә;

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны коммерцияләштерү циклын кыскартуга;

предприятиеләрнең уйлап табу активлыгын арттыруга һәм Татарстан Республикасы икътисады тармакларының фәнни-технологик үсешен стимуллаштыруга;

сату базарларына инновацион проектларны чыгаруга һәм җитештерү өлкәсенә инновацияләр кертүгә, бу бюджетның барлык дәрәҗәләренә салым керемнәренең артуына китерәчәк.

Интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен халыкара нормалар нигезендә формалаштыру республика товар җитештерүчеләренең халыкара конкурентлык сәләтен һәм интеллектуаль милекне саклауның эшли торган механизмы булган территория буларак республиканың инвестицион җәлеп итүчәнлеген сизелерлек арттырачак. Шул ук вакытта Татарстан Республикасында чит ил көндәшләренә бәйле булуыннан саклау механизмнары формалаштырылачак.»;

6 нчы ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин